ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**КАРАР**

19.11.2024 г.Казань № 331-4/э-2024

«Татнефть – Энергосбыт» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте һәм «Сетевая компания» акционерлык җәмгыяте челтәр оешмалары арасында үзара исәп-хисаплар ясау өчен электр энергиясе тапшыру хезмәте күрсәтүгә 2025 елга индивидуаль тарифлар билгеләү хакында

«Электр энергетикасы турында» 2003 елның 26 мартындагы 35-ФЗ номерлы федераль законга, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Электр энергетикасында җайга салынулы бәяләр (тарифлар) өлкәсендә бәя кую турында» 2011 елның 29 декабрендәге 1178 номерлы карарына, Федераль тарифлар хезмәтенең «Ваклап сату (кулланучылар) базарында электр (җылылык) энергиясенә җайга салынулы тарифлар һәм бәяләр хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2004 елның 6 августындагы 20-э/2 номерлы һәм «Электр энергиясен тапшыру хезмәтләренә зарури тулай табышны озак вакытлы индексацияләү методын кулланып билгеләнә торган тарифларны хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2012 елның 17 февралендәге 98-э номерлы боерыкларына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмәгә туры китереп, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсенең 2024 елның 19 ноябрендәге 27-ПР утырыш беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2025 елның 1 гыйнварыннан 2025 елның 31 декабренә кадәр «Татнефть – Энергосбыт» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте белән «Сетевая компания» акционерлык җәмгыяте челтәр оешмалары арасында үзара исәп-хисаплар ясау өчен электр энергиясен тапшыру хезмәте күрсәтүгә, шушы карарның 1 нче кушымтасына туры китереп, календарь буенча бүленгән индивидуаль тарифлар билгеләргә.

2. Әлеге карарның 2 нче кушымтасына туры китереп, «Татнефть – Энергосбыт» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең 2025 елга кирәкле тулай керемен (югалтуларга түләүне исәпкә алмыйча) билгеләргә.

3. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы С.В. Павлов

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
19.11.2024 № 331-4/э-2024
карарына 1 нче кушымта

2025 елның 1 гыйнварыннан 2025 елның 31 декабренә кадәр Татарстан Республикасы территориясендә «Татнефть – Энергосбыт» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте һәм «Сетевая компания» акционерлык җәмгыяте челтәр оешмалары арасында үзара исәп-хисап ясау өчен электр энергиясен тапшыру хезмәте күрсәтүгә календарь буенча бүленгән индивидуаль тарифлар

<table>
<tr><th rowspan="4">Т/с</th><th rowspan="4">Челтәр оешмасының исеме</th><th rowspan="4">Ел</th><th colspan="3">1 гыйнвардан 30 июньгә кадәр</th><th colspan="3">1 июльдән 31 декабрьгә кадәр</th></tr>
<tr><th colspan="2">Ике ставкалы тариф</th><th rowspan="2">Бер ставкалы тариф</th><th colspan="2">Ике ставкалы тариф</th><th rowspan="2">Бер ставкалы тариф</th></tr>
<tr><th>Электр челтәрләрен карап тоту ставкасы</th><th>Технологик чыгым (югалту) өчен түләү ставкасы</th><th>Электр челтәрләрен карап тоту ставкасы</th><th>Технологик чыгым (югалту) өчен түләү ставкасы</th></tr>
<tr><th>сум/МВт·ай</th><th>сум/МВт·сәг</th><th>сум/кВт·сәг</th><th>сум/МВт·ай</th><th>сум/МВт·сәг</th><th>сум/кВт·сәг</th></tr>
<tr><td>1.</td><td>«Татнефть – Энергосбыт» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте – «Сетевая компания» акционерлык җәмгыяте</td><td>2025</td><td>49 162,06</td><td>26,8377</td><td>0,18422</td><td>49 162,06</td><td>26,8377</td><td>0,18422</td></tr>
</table>

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының
тариф карарларын кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм
теркәү бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
19.11.2024 № 331-4/э-2024
карарына 2 нче кушымта

2025 елга «Татнефть – Энергосбыт» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең кирәкле тулай кереме (югалтулар өчен түләүне исәпкә алмыйча)

| т/с | Татарстан Республикасында челтәр оешмасының исеме | Ел | Челтәр оешмасының кирәкле тулай табышы (югалтуларга түләүне исәпкә алмыйча) |
|---|---|---|---|
| | | | мең сум |
| 1. | «Татнефть – Энергосбыт» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте | 2025 | 986 151,54 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тариф карарларын кабул итүне
оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге